ГЛАВА СОБОЛЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ СОБОЛЕВСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Ул. Советская, д.7, с. Шеланга, 422577

Совет ур., 7 нче йорт, Шеланга авылы, 422577

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

с. Соболевское

05.11.2025

№ 2

«Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Уставы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 нче елның 19 нчы ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Авыл яны территориясендә гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Карамышиха авылы, Үзәк урамы, 5А йорт 10:00 сәгатьтә.
4. Соболевский авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районының
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О.Н.Майорова